СОВЕТ
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Ул. Центральная, д.55, с. Введенская Слобода, 422591
Үзәк ур., 55 нче йорт, Введенский бистәсе авылы, 422591
Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

---

**РЕШЕНИЕ** | **КАРАР**

29.05.2024 с. Введенская Слобода №36-301

Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пунктына ярашлы рәвештә, җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсезлекне җайга салу максатыннан,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Введенсий Бистәсе авыл җирлеге Советы
КАРАР ИТТЕ:

1. Җирле салымнар суммасы буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә.
2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә караган, түләү һәм (яки) түләтү түбәндәге нигезләр буенча мөмкин булмаган җирле салымнар суммалары өлешендә бурыч өметсез дип таныла:
1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки вафат булган дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;
2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;
3) физик затларда Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.
2. Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып:
1) әлеге карарның 2 статьясының 1 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:
а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;
б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;
в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;
2) әлеге карарның 1 статьясының 2 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) оешманың, шәхси эшмәкәрнең, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затның исәпкә алу урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;
б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;
3) әлеге карарның 1 статьясының 3 пунктында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу турында белешмәсе.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Введенсий Бистәсе авыл җирлеге Советының 2023 елның 24 июнендәге N 27-258 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (игълан ителгән) көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматларының рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Введенсий Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов